СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.06.2023 г.Зеленодольск № 118

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 2021 елның 17 декабрендәге 68 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2022 елның 24 мартындагы Зеленодольск шәһәре Советының 75 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» Федераль законның 2 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 18 мартындагы 71-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең Торак кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 2021 елның 17 декабрендәге 68 номерлы карары белән (2022 елның 24 мартындагы Зеленодольск шәһәре Советының 75 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктында «энергетика нәтиҗәлелеген» сүзләреннән соң «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында законнар» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. Нигезләмәнең 1.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

«12) йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын куркынычсыз эксплуатацияләүгә һәм техник хезмәт күрсәтүгә таләпләр, шулай ук күп фатирлы йортта гомуми милеккә караган вентиляция һәм төтен каналларын тотуга таләпләр.».

2. Әлеге карар 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo. tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми Порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk. tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре Мэры,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА ИНН 1648017849 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ